Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN

УНИВЕРСИТЕТ

№ 19 (32)

14 июнь 2012 ел

## • Ике авыз сүз

7 июнь көнне ректор И.Гафуров җитәкчелегендә **КФУның ЧИРАТТАГЫ РЕКТОРАТ УТЫРЫШЫ УЗДЫ**. Көн кадагына 6 сорау куелган иде, икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор М.Сафиуллин өчесенә җавап бирде. Ул КФУ ның Үсеш программасын тормышка ашыру буенча эшләнелгән эшләр турында әйтеп узды, шулай ук Коллектив куллану үзәге һәм Әхлак комитеты оешуы турында хәбәр итте.

Утырышта кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе С.Ионенко да кабул итү кампаниясенең инде әзер булуы турында искәртте. 13 июньнән «Абитуриент» мәгълүмати системасы эшли башлаячак. Әлегә бу тест режимында гына булачак, 18 июньнән ул тулаем эшләп китәр дигән ниятә торалар. Моннан тыш абитуриентлар массакүләм мәгълүмат чаралары, КФУ сайты һ.б. социаль челтәрләр ярдәмендә җәлеп ителә. Сәгать 8.30 дан 19.00 га кадәр күп каналлы Call-үзәк хезмәт итәчәк. И.Гафуров шалтыратуларны кич белән автоматик рәвештә кабул итәргә дигән тәкъдим ясады, ә документларны кабул итү башлангач (20 июньнән башлап), II корпустагы Мәрмәр залга 6 инфомат һәм WI-FI урнаштырылачак.

КФУда яңа структур бүленеш – дәүләт идарә итү мәктәбе барлыкка килде. Аның турында ректорат утырышында дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең белемен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге директоры Л.Нургатина сөйләде. Аның сүзләренчә, әлеге мәктәп эффектив һәм намус белән эшли торган элитаны ТРда гына түгел, Идел буе федераль округында да әзерлиячәк.

Соңгы сорау буенча журналистика һәм социология факультеты деканы В.Гарифуллин факультетта социологик тикшеренүләр лабораториясен ачу турында мәгълүмат җиткерде.

Утырыш азагында И.Гафуров КФУ ның факультет һәм институт җитәкчеләренә югары һәм чыгарылыш курс студентларының белемнәрен тикшерү уңаеннан ясалырга тиешле тестларны әзерләргә кирәклеген әйтте. Тикшерүне III курстан башлап кертергә планлаштыралар.

• • • •

7 июнь көнне КФУ ның Яр Чаллы филиалында вузара **«УРТАК ГРАЖДАНЛЫК ПОЗИЦИЯСЕ ФОРМАЛАШУ: ПРОБЛЕМАЛАР, ЗАМАНЧА ТОРЫШ, ПЕРСПЕКТИВАЛАР» ТЕМАСЫНА «ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ» УЗДЫ**. «Түгәрәк өстәл»дә катнашучылар күтәрелгән проблемаларның хәзерге сәяси фәннәр өчен бик нәтиҗәле, актуаль булуын ассызыклап үтте. Утырышта Европадагы күпмәдәниятлелек, Россиядәге этносәясәт, аның чынбарлыгы турындагы фикерләр дә яңгырады. Икенче көнне А.Большаковның «Гражданлык җәмгыятенең куркынычсызлыгына янау буларак терроризм» исемле лекциясе бу «түгәрәк өстәл»нең дәвамы буларак оештырылды. Әлеге лекциядә студент-политологлар, укытучылар, мәктәп укучылары катнашты.

• • • •

Шушы көннәрдә КФУ ның **ЯР ЧАЛЛЫ ФИЛИАЛЫ ҮЗЕНЕҢ 15 ЯШЬЛЕГЕН БИЛГЕЛӘП ҮТТЕ**. Бу уңайдан күп еллар буе филиалның үсеше өчен көч куйган хезмәткәрләр, укытучылар диплом һәм мактау кәгазьләре белән бүләкләнде. Мөхтәрәм кунаклар арасында М.Сәләхов, Р.Хәмитов, Е.Шуралева, Ф.Мостафина, Л.Яһудина, Т.Чернышевалар бар иде. Укытучыларын котларга дип төрле елларны бетереп чыккан студентлар да килгән иде. Бәйрәм уңаеннан шулай ук Мәскәү дәүләт университеты, Ю.Либиг исемендәге Гиссен университеты (Германия), Астана дәүләт университеты һәм Чуваш дәүләт университетларыннан да котлаулар җибәрелгән. Филиалның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәгенә багышланган махсус фильм да төшерелгән.

• • • •

Шушы көннәрдә «КамАЗ»ның генераль директоры **СЕРГЕЙ КОГОГИН КФУ РЕКТОРЫ ИЛШАТ ГАФУРОВ БЕЛӘН ОЧРАШТЫ**. Алар Яр Чаллыда күп еллар «КамАЗ»га кадрлар әзерләгән Кама дәүләт инженерия-икътисад академиясенең КФУга кушылуы турында сөйләштеләр. И.Гафуров фикеренчә, әлеге кушылу яңартылган уку йортының позицияләрен ныгытачак һәм студентлар көчле матди-техник база белән тәэмин ителәчәк.

• • • •

11 июнь көнне тышкы элемтәләр буенча проректор Л.Латыйпов җитәкчелегендәге **КФУ ДЕЛЕГАЦИЯСЕНЕҢ Ю.ЛИБИГ ИСЕМЕНДӘГЕ ГИССЕН УНИВЕРСИТЕТЫНА (ГЕРМАНИЯ) РОССИЯ АТНАЛЫГЫНА БАГЫШЛАНГАН ВИЗИТЫ БАШЛАНДЫ**. Атналыкны ачу тантанасында кунакларны мәртәбәле галимнәр сәламләде. 12 июнь көнне «Россиядә икътисади һәм мәдәни күпкырлылык» дигән фәнни симпозиум эшләде. Ул Казан университеты белән күпьеллык хезмәттәшлек нәтиҗәсе булып тора. Симпозиум барышында Казан һәм Гиссен галимнәре хезмәттәшлек итүнең яңа юнәлешләре турында да сөйләште.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Әмир Фазлыйәхмәтов фотосы

# Ул миңа кагыла!

**Алинә САДЫЙКОВА, Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрчеләр

2005 елның маенда Бөтендөнья сәламәтлек ассамблеясе вакытында төрле илләрнең сәламәтлекне саклау министрлары 14 июньне дөньякүләм кан донорлары көне итеп билгеләргә дигән фикергә киләләр.

Дөньякүләм кан донорлары көне эчкерсез, кире берни дә таләп итмичә генә билгеләнеп үтүе белән үзенчәлекле. Әлеге чарада 193 Берләшкән милләтләр оешмасы дәүләте, 181 Кызыл Хаҗ һәм Ярымай милли җәмгыятьләре, 50 дән артык донорлык оешмалары катнаша.

2005 елдан бирле Казанда 8 шундый масштаблы акция уздырылган. Анда 200 дән артык студент катнашып, 300 литрдан артык кан биргән. Студентлар яшьләрне әлеге изге эшкә җәлеп итү өчен интернет челтәрендә актив эшчәнлек алып бара. Казан университетының чыгарылыш студенты Руслан Шәкүров «Вконтакте» сайтында «Кан донорларын эзләү» төркемен булдырган. Бүгенге көндә бирегә 4500 дән артык кеше исәпләнә. Россиядәге донорлар җитмәү проблемасын хәл итүгә әлеге төркем аз гына булса да үз өлешен кертә дип уйларга җирлек бар.

ТР Сәламәтлекне саклау министрлыгы кан күчереп салу станциясенең баш табибы Рамил Тураев билгеләп үткәнчә, донор булып кан биргән кешеләрдә зур потенциал бар, алар гомерләрендә дә күрмәгән кешеләргә ярдәм итәләр. «Без үз алдыбызга аз яисә күп итеп кан алырга дигән максат куймыйбыз. Иң мөһиме – яшьләрне бу яхшы һәм миһербанлы эшкә тарту. Мондый акциядә катнашкан егетләр һәм кызлар, алга таба да каннарын бирep, башкаларның гомерләрен коткарырлар дип ышанам. Безнең төп максат – яшь донорларның сафын арттыру», – дип фикерләре белән уртаклашты Р.Тураев.

Әлеге эшкә бары тик зур хәрефле Кеше генә сәләтле. Россия Федерациясенең 18 яше тулган һәр сәламәт гражданины донор була ала, ләкин аның гәүдә авырлыгы 50 кг ким булырга тиеш түгел. Кан тапшырыр алдыннан махсус медицина тикшеренүе үтү мөһим. Шулай ук донорлыкка каршы килердәй берничә авыруны истән чыгармаска кирәк: ВИЧ-инфекция, сифилис, вируслы гепатит, туберкулез, кан, онкология авырулары һ.б. Кан бирә алмаган кешеләр кәефен төшерергә ашыкмасыннар, чөнки донорлык акцияләрен уздырырга, әлеге эштә ярдәм итәргә волонтерлар һәрвакыт кирәк.

Донорлык турында төрле мифлар да йөри. Табиблар әйтүенчә, аларның берсенә дә ышанырга ярамый. Иң мөһиме: «Ул миңа кагылмый», – дигән сүзләрдән ерак торсак иде, чөнки кешегә уйламаганда кан кирәк булуы бар. Статистик мәгълүматларга караганда, һәр өченче кеше үз гомерендә кан алыштыруга дучар була. Шуңа күрә сез дә донор була һәм башкаларга ярдәм итә аласыз.

## • Яңа китап

# Тормышны - объектив аша

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Шушы көннәрдә генә журналистика һәм социология факультеты доценты Җәүдәт Акчуринның «Заманча журналистика нигезләре» дип исемләнгән кулланмасы дөнья күрде.

Бүген тирә-яктагы гүзәллекне, кешеләр тормышын фотосурәткә төшерү популярлашып китте. Яшьләр бу өлкәдә аеруча актив. Бары тик сәләтне күреп, дөрес юнәлеш бирергә кирәк. Шуңа күрә иҗади процесс вакытында реаль тормыштагы махсус сурәтләү чараларын тотып алып, фотокамера ярдәмендә шәхси күзлектән карый торган тормыш кысаларына кертә белү осталыгына өйрәтү мөһим. Моның өчен китаплар, махус курслар, индивидуаль дәресләр ярдәмгә килә.

Галимнең әлеге өлкәгә ничек кереп китүе, басма турында тулырак алдагы санда укый аласыз.



• Бездә кунак бар

# Федераль агент булабызмы?

**Динә МӨХТӘСИПОВА,**
хәбәрче

8 июнь көнне Казан университетына «Ачык икътисад» икътисади тикшеренүләр һәм икътисади мәгълүмат тарату үзәге директоры Константин Киселев килде.



Алия Галимуллина фотосы

Визит барышында ул Технопаркта булды, Физика институты, А.М.Бутлеров исемендәге Химия институтында лабораторияләр белән танышты.

«Казан – иң яраткан шәһәрләремнең берсе. Минемчә, Россия Федерациясенең һәр гражданины өчен бу шәһәр – изге урын, чөнки биредә ничә гасырлар дәвамында төрле халыкларның традицияләре, мәдәнияте, дине сакланып килә. Казан шулай ук иң эре мәгариф һәм сәнәгать үзәге дә», – дип хис-кичерешләре белән уртаклашты кунак.

Аның безгә килүенең төп максаты: Казан федераль университетында эшләүче галим-укытучылар һәм берничә вузны кушкач барлыкка килгән уку йорты эшчәнлеге белән танышу иде. «Бүген күргәннәремнән нәтиҗә ясап әйтсәм, Казан федераль университеты, ике гасырлык тарихына таянып, Татарстан Республикасында федераль агент функциясен үти ала, шулай ук фәнни-инновацион процессларны тормышка ашыру өчен дә мөмкинлекләр җитәрлек. Студентларга социаль-мәдәни, рухи һәм әхлакый яктан үсәргә дә бөтен шартлар бар», – дип ассызыклады.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы хакимият органнары вәкилләре белән дә очрашу булды. Анда безнең университеттан икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор Марат Сафиуллин катнашты. Утырыш вакытында Казан федераль университетының Идел буе федераль округында ничек үсәчәге турында сөйләшенде. Константин Киселев сүзләренчә, округтагы төбәкләр белән килешүләр төзергә кирәк. Бу социаль-икътисади яктан үсәргә ярдәм итәчәк.

*Матбугат үзәге мәгълүматлары файдаланылды.*

• Мәсьәләгә бер караш

# Эшкә биреп бар күңел...

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

Катлаулы имтиханнар, таләпчән укытучылар, университет – болар барысы да артта калды, алда зур тормыш көтә. Кичә студент булганнарның барысында да бер проблема: эш табу.

Теләгән эшне тапканнан соң, икенче проблема килеп баса – әңгәмә үтү. Күпләр бу сүздән куркалар, әмма берничә гади кагыйдәне истән чыгармасаң, аның бернинди куркынычы да юк.

**Беренчедән,** төгәл булу сорала. Очрашуга соңга калу – җавапсызлык билгесе. Әгәр өлгермисең икән, бу очракта шалтыратып, кисәтеп кую әйбәт булыр. Шулай да алдан ук юлга күпме вакыт сарыф ителәчәген исәпләп, очрашу билгеләнгән урынга 10-15 минут алдан килсәң, андагы тирәлекне күзәтергә, бер кат ияләшергә вакыт булачак.



**Икенчедән**, үзең турында яхшы фикер калдырырга кирәк. Сөйләм ипле, ачык, төгәл, тавыш нык булсын. Ешрак елмаерга, үзеңнең көчле якларың, сәләтләрең турында сөйли белергә туры киләчәк. Шулай ук тышкы кыяфәт турында да онытырга ярамый. Кигән кием җайлы, гади, макияж артык «кычкырып тормаска» тиеш, чәчең пөхтә итеп җыелган булса, яхшы фикер калдырырга җиңелрәк булачак.

**Өченчедән**, сорауларга җавапны инде алдан ук әзерләп куя аласың. Сораулар күп һәм төрле характерда булырга мөмкин, әмма һәркемгә бирелә торган стандарт булганнары да бар.

**Дүртенчедән**, үз сорауларыңны да бирергә кирәк. Әңгәмәгә барыр алдыннан эшләячәк оешма турында билгеле бер күләмдә хәбәрдар булу да зарури, тик әңгәмә вакытында сораулар туарга яисә кайбер моментны аңлап бетермәгән очрак булырга мөмкин. Бу вакытта курыкмыйча, үзеңне кызыксындырган сорауларны бирү нормаль күренеш.

Кешеләрнең төрле характерда булуын да онытмаска кирәк Кемдер аралашучан, экстрим яратучан, эмоциональ, ачык. Ә кайберәүләр, киресенчә, ыгы-зыгыны күрә алмый, бөтен эшне дә алдан планлаштырып, кирәгеннән артык кайгыручан булалар. Шуңа бәйле ике психологик типны аерып чыгаралар: экстравертлар һәм интровертлар.

Экстравертлар үзләрен бөтен яклап та күрсәтеп калырга тырышалар, бик теләп аралашалар, бер урында гына торырга яратмыйлар, аларга гел нинди дә булса үзгәреш кирәк. Психологлар мондый кешеләргә әңгәмә вакытында чуар кием кимәскә; сөйләм вакытында эмоциональлеккә бирелмичә, сорауларга төгәл, логик уйланылган җавап бирергә; тыныч, нейтраль тавыш белән сөйләшергә киңәш итә. Интровертлар исә тыныч тирәлекне яраталар. Аларга күп кешеләр белән аралашырга туры килми торган, индивидуаль эшчәнлек алып бара алырдай, төпле фикергә килер өчен билгеле бер вакыт таләп итә торган, җаваплы эш туры килә. Бу төр психологик типка мондыйрак киңәшләр биреп була: әңгәмә алдыннан дуслары яисә якыннары белән сорауларга җавап бирүне кабатларга; ешрак елмаерга; әңгәмәдәшенең күзләренә карап сөйләшергә, үзеңнең резюмеңны карап алырга мөмкин – бу кирәк булмаган, озын паузалардан коткарачак.

Әлеге бүленеш кемдер яхшырак, кемдер начаррак дигән сүз түгел, бары тик үз юнәлешеңне табу өчен бер ярдәмлек кенә. Кемдер бер эшне яхшырак эшли, ә кемгәдер башкасы җиңелрәк бирелә. Ничек кенә булмасын, иң элек үз көчеңә ышану, яхшы кәеф, эшләү теләге кирәк. Әгәр син үз-үзеңә ышанасың икән, башкаларны да инандыру җиңел булачак.

• Студент колагына

# Җәй сессиядән соң башлана!

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Җәйге сессия чоры тәмамлану белән, шау-гөр килеп торган шәһәр тынычланып кала. Каникуллар җитә бит. Студентларның да кайсы-кая таралышып бетә. Әлбәттә, ялларны ничек, кайда үткәрү һәркемнең үз эше. Шуңа карамастан, уйлап-уйлап та бернинди фикергә килә алмаганнар өчен кайбер киңәшләребез бар.

Беренчедән, бер-ике атнага булса да авылдагы әби-бабайларыгыз янына кайтып килергә тырышыгыз. Авыл җирендә эш күп анысы, сүз дә юк. Ә шулай да, әбибабайга булышып, җәйге авыл һавасын күкрәк тутырып сулауга берни дә җитә алмый!

Икенчедән, уку елы дәвамында карый алмаган фильмнарыгызны барлап чыгыгыз. Нәрсә эшләргә белми аптырап йөргәндә, һичьюгы кино карарга була!

Өченчедән, эшкә урнашырга мөмкин! Бик күп студентлар җәй көне акча эшләп калырга ашыга. Ә вакытлы эшкә урнашу өчен җәй менә дигән вакыт!

Ә инде мөмкинлекләре булган студентлар, башка шәһәрдәге туганнарында, я булмаса чит илгә барып ял итәргә тырыша. Безнең студентларыбызның планнары нинди рәк икән соң? Без кечкенә генә сораштыру үткәрдек.



**Ландыш Рәхимуллина,** Фундаменталь медицина һәм биология институты студенты:

«Сессиянең бетүен түземсезләнеп көтәм. Быелгы җәем башкаларыннан үзгәрәк булыр дип уйлыйм, җылы якларга барырга планлаштырам».



**Динара Шәкүрова,** Педагогика һәм психология институты студенты:

«Җәй, миңа калса, нииндидер яңалык алып килергә тиеш. Ул – ел дәвамына җитәрлек энергия туплау чоры. Шуңа да быел күптәнге хыялым – Санкт-Петербург шәһәренә сәяхәткә барырга уйлыйм».



**Алинә Мусина**, Филология һәм сәнгать институты студенты:

«Кемгә ничектер, ләкин мин җәй буе тик кенә ята алмыйм! Һәр елны берәр җиргә эшкә урнашам. Быел да үземә ошаган эш белән шөгыльләнәчәкмен! Вакытым да бушка үтмәс, аз булса да акча эшләрмен».



**Алинә Арсланова,** КДМУ студенты:

«Безнең ял вакыты августка гына туры килә. Башта сессия, июль аенда практика үтәбез. Ә бер ай вакытымны ялга, бары тик туган ягыма кайтып, шәһәр шаукымыннан тынычлап ял итүгә багышлыйсым килә».



**Гөлгенә Әминова,** Филология һәм сәнгать институты студенты:

«Минем бу җәем онытылмаслык булыр дип ышанам. Яраткан кешем Төркиягә юлламалар алган. 10 көнлек сәяхәтебез күңелле, мәҗараларга бай, онытылмаслык булыр дип өметләнәм, бары тик ышанырга гына кирәк!»

Һәркемнең планнары үзенчәлекле. Җәйге ялларыбыз бушка үтмәсен: файдалы да, кызыклы да һәм нинди дер истәлекләр алып килердәй булсын иде! Кышкы салкын кичләрдә, җәй җылылыгын биреп торган фотоларны алып, үткән мизгелләргә сокланып караудан да рәхәтрәк нәрсә юк бит! Һәм иң мөһиме: яңа уку елына яңа көчләр җыеп килергә язсын!

● Бәйрәмнәребез

# Тамырлар кая тоташа?

Сабан туе – татар халкының җанлы гәүдәләнеше, аерылгысыз хасияте, традицион культурасының йөзек кашы. Сабан туе, Җыен кебек бәйрәмнәрнең бик борынгы заманнарга ук китүче тирән тамырлары бар.

**Гамирҗан ДӘҮЛӘТШИН,**
тарих фәннәре докторы, профессор





Ул болгар бабаларыбызда Җучи Олысы чорында да бәйрәм ителгән булса кирәк. Бер болгар-татар кабер ташъязмасында мәрхүмнең үлгән көне турында «Сабантуй көн иде» диелә. Бу ташъязмаларны өйрәнүче, укучы галим Ф.Хәкимҗанов әлеге язмада телгә алынган мәрхүмнең 1292 елның 15 июнендә үлүен әйтә. Белүебезчә, бу хәзер дә Сабан туйлары чорына карый. Әмма монда иң әһәмиятлесе шунда: бу чорда ук Сабантуй көне календарь, вакыт ориентирына әверелгән, борынгыдан килеп, тотрыклы күренешкә, болгар-татар тормышында иң әһәмиятле бөтен халык вакыйга-бәйрәменә әйләнгән. Әле XIX-XX гасырның беренче яртыларында да ел әйләнәсендәге вакыйгалар безнең татар халкында «Сабантуйга кадәр» һәм «Сабантуйдан соң» булган чорларга бүленгән.

Шундый бөтен халык бәйрәме хакында XVI гасырның беренче яртысында Казанда 20 ел яшәгән исеме билгесез, әмма «Казан тарихы» исемле күләмле китап язып калдырган рус авторы да искә ала. Ул Казан халкының сәйранда зур бәйрәмдә күңел ачулары хакында яза: «Патша һәм аның якыннары – аксөякләр корбан итеп симез үгезләр чалалар. Ә гади, кара халык сарык-тәкә, тавык корбан итеп чала. Һәм шуннан соң гомум күңел ачу, шатлык башлана. Йөз-битләрен ясанып, гөслә, кубызларда уйнап, матур җырлар башкаралар, кулларын чәбәкләп, сикерә-сикерә бииләр». Әлеге бәйрәм корбан чалулар белән мөселман «Корбан бәйрәменә» тартым кебек. Әмма бию, җырлар белән ул гомум күңел ачуга кайтып кала. Бу, беренче чиратта, Сабантуйга тартым. Аның үткәрелү вакыты да сабантуйлар вакытына туры килә.

Әмма Сабантуй үзенең хасияте, тамырлары белән тагын да борынгырак чорларга китә. Аның тамырларына төшәргә күп кенә татар, рус галимнәре омтылыш ясап карады. Берәүләр Сабантуйның беренчел мәгънәсен язгы чәчүгә яки аграр культ белән бәйле болгар бәйрәме (Н.Загоскин, Г.Әхмәров, Я.Коблов, Р.Кәшәфетдинов, Р.Уразманова, Я.Ханбиков, Г.Бәширов), икенчеләр – яз бәйрәме (П.Рычков, Д.Асылов), өченчеләр «уянып килүче табигатькә гимн, югары, күк алласы – Тәңрегә табыну» (Б.Урманче) рәвешендә аңлаталар. Шулай итеп, күпчелек тикшеренүчеләр, нигездә, аның исеменә генә игътибар итеп, бу бәйрәмне сабан, язгы чәчү бәйрәме буларак карыйлар. Комплекслы чыганакларга нигезләнеп, борынгы карашлар белән бәйләп, татар милли бәйрәме Сабантуй тулырак рәвештә тарих фәннәре докторы Д.Шәрәфетдинов хезмәтләрендә тикшерелә. Автор Сабантуй – уянып килүче табигатькә, язгы чәчүгә бәйле борынгы календарь бәйрәм, дип яза.

### Асылда ни ята?

Сабан туен күпчелек галимнәр игенчелек белән бәйләп карасалар да, бәйрәм-йоланың җисеме түгел, исеме генә чәчүне күз алдына китерә. Әмма Сабантуйның үз хасиятендә игенчелеккә, чәчүгә ишарә дә юк. Киресенчә, ул күчмә кабиләләр йоласына тартым (ат табанын кыздыру йоласы, ат чабышлары һ.б.). Шуның өчен дә, күрәсең, борынгылыкта аның исеме дә икенче мәгънәне аңлаткан булса кирәк. Дөрес, Сабантуй борынгы дәверләрдә барлыкка килгәнчә генә сакланмаган, һәр чорда үзгәреш кичергән. Игенчелек алга киткән Идел буе Болгар дәүләтендә Сабантуй язгы чәчү бәйрәме, сөрүлек җирләрне хөрмәтләү бәйрәме буларак яңа төсмер алган булуы мөмкин.

Әмма аның әлеге хасияте, ясалма рәвештә аеруча совет чорында күпертелеп, сәясәт белән бәйләп, «кырлар батырын» данлау өчен генә эшләнде. Шул рәвешле, бу бөек бәйрәмнең киң, югары эчтәлеге чикләнде.

Сабантуй – туган җиргә, табигатькә, тормышка дан җырлаган бәйрәм.

Һуннар, борынгы төркиләр үзләренең туган илләрен, җирләрен яратуны да культ дәрәҗәсенә җиткергәннәр. Аларда туган җирне ярату шул кадәрле көчле булган ки, хәтта аның аерым алласы да билгеләнгән. Бу – Урта, Җир өсте алласы – «Удук Йир-Суб» (изге җир-су), «Җир-су» – туган җирнең, илнең синонимы. Аның культы тау, кыя, күл, елга, җир ияләренә баш ию белән бәйле. Бу – табигатькә, «туган ягым – яшел бишек»кә Аллага баш игән кебек табыну. Изге таулар, биеклекләр, биек ялгыз агачлар да «Җир-су» культының аерылгысыз бер өлеше булган. Биек таулар һәм агачлар Җир белән Күкне, Тәңре белән аңа табынучы кешеләрне тоташтырган. Н.Бичурин Кытай елъязмасы «Вейшу»дан төркиләрнең Бодын-инли дип аталган башы шәрә биек тауны изгеләштерүләре хакындагы хәбәрне китерә. Көнчыгыш Төрки каганлыгы каганнары һәм халкы «Күк рухына» биек тауда табынганнар. Аның исеме «ил химаячесенең рухы» дигәнне белдерә икән. Димәк, бу тау һәм аның рухы ил иминлеген саклый дип ышанганнар. Тау атамасындагы «бодын-будун» борынгы төрки язмаларда «халык, ил» дигәнне аңлата. Шунысы гыйбрәтле: соңгы чорларга кадәр авыл аксакаллары Сабантуй уздырыр өчен урынны тау башында яки тау итәгендә сайлаганнар. Сабантуй репертуарында хәтта «тауга каршы йөгереш» ярышы булуы да мәгълүм. Элек Мамадыш төбәгендә, Сабантуй башлануын хәбәр итеп, тау башына ут ягу гадәте булган.

Борынгы төркиләр зур горурлык белән үзләренең туган җирләрен «төркиләрнең җирсулары» дип йөрткәннәр. VI гасыр Византия тарихчысы Феофилакт Симокатта борынгы төркиләр турында «алар җиргә дан җырлыйлар», дип язган. Алардагы тылсымчылар «җирне чакыралар», ягъни җиргә эндәшеп, аның көчен сорыйлар, дип өсти. Туган җирне «җир-су» дип атау телебездә бүген дә кулланылышта. Телебездә туган җирне бик нык сагынуны белдерә торган тагын бер сүз бар: җирсү, җирсенү. Бу сүзләрнең җир-су сүзе, төшенчәсе һәм борынгы Җир-Су алласы белән бәйле булуы әллә ни шик тудырмый. Җиргә табыну халкыбызда соңгы чорларга кадәр дәвам иткән. Аңа багышлап төрле йолалар үткәргәннәр, аны искә алып ант иткәннәр: «Җир йотсын». Бу ант, сүзне раслау рәвешендәге гыйбарәне без бүген дә кулланабыз. «Йоту» фигыле, билгеле, туры мәгънәдә җан ияләренә нисбәтле әйтелә. Димәк, антында, сүзеңдә тормасаң, сине Җир (бик зур җан иясе) йотырга мөмкин. «Җир тота» да. Аның бу сыйфаты «Кыйссаи Йосыф»та ук теркәлгән. Зиндандагы Йосыфка хәбәр китергән гарәп дөясенә сугарга дип ниятләгәч, «аягын җир тота». Гарәп тәүбә кылгач кына, «аякларын җир җибәрә». Бу борынгы «Удук йир-суб» кыяфәтен төсмерләү дә кебек. Халкыбыз келәүләрендә дә аңа илаһи затка мөрәҗәгать иткән кебек эндәшелә. Аңарда кешегә хас кыяфәтләр дә чалымлана: *«Җир атасы – җирән сакал! Җир анасы – асыл бикә!»*

Шулай итеп, борынгы бабаларыбызда Туган ил Туган җир төшенчәсе белән аерылгысыз бәйләнештә була. Хәтта бу төшенчәләргә караган махсус Җир-Су алласы да була. Ләкин борынгы төркиләр, моның белән генә чикләнеп калмыйча, аңа көчле иҗтимагый аһәң бирәләр. Безнең экологик киеренкелек чорында мондый идеология аеруча актуаль.

Югарыда китерелгәннәрнең барсы да безнең Сабантуй бәйрәменең асыл рухын, үзәк хасиятен тәшкил итә.

### Тәкә культы

Инде Сабантуйның символик иң зур бүләге – тәкәгә килик. Төрки татарларда культка әйләнгән бу хайван борынгы бабаларыбыз карашында тотем хайваннан алып Сабантуй батырына бирелә торган иң зур призга җитәрлек юлны узган.

Борынгы төркиләрдә тәкә иң культлаштырыла торган һәм Тәңрегә, Күккә, Кояшка иң кулай корбан хайваннардан саналган. Аның культы алга таба да дәвам итә. Болгар, угыз, кыргыз кабиләләрендә изге хайван санала. Потка охшаш тәкә сыннары болгар археологик материаллары арасында да еш табыла.

Шулар арасыннан Биләрдә табылган зур мөгезле тәкә башы кыяфәтле куыш керамик фигура-су сипкеч игътибарны үзенә җәлеп итә (рәсемдә). Гомумән, бу – дәһшәтле, беркадәр куркыныч сын. Күрәсең, ул табына торган сындыр. Безнең карашыбызча, ул болгарларда корылык чорында «Яңгыр чакыру, яңгыр теләү» магик инструмент ролен үтәгән булырга тиеш. Рухи яктан Тәңре белән иң тыгыз бәйле хайван – тәкә. Ә яңгыр – Тәңре кодрәтендә.

Хәзер дә телебездәге «Алланың кашка тәкәсеме әллә син?» дигән гыйбарә дә тәкәнең борынгылыкта Тәңрегә нисбәтле хайван булуы һәм аның культы хакында сөйли. С.Кляшторный фикеренә караганда, Икенче төрки династиянең (683-744) (шул вакытта Икенче Төрки каганлыкның да) геральдик билгесе «башы ромб шәкелендәге тәкә» сурәте булган. 733 елда төзелеп бетеп, борынгы төркиләрнең гаскәр башлыгы, тәхет варисы, Билге каганның энесе Күлтәгингә куелган мемориаль комплекс һәм андагы язмалар бик мәһабәт. Аңа керә торган капка янында мәрмәрдән бер-берсенә каракаршы торган ике тәкә сыны (рәсемдә) куелган. Мондый сурәт Капаган каганга куелган дип уйланган мемориаль комплекстагы ташбака сынының ян-ягына төшерелгән.

Татарларда «Күк тәкәсе»нә (борынгы мәгънәдә – «Тәңре тәкәсе») ышану яшәгән. Аңа махсус җыен багышланган («Күк тәкә җыены»). Сабантуй һәм Җыен тора-бара бер бәйрәм булып кушылалар. Әмма борынгы чорларда Сабантуй, беренче чиратта, ирләр бәйрәме саналган, киләчәк сынауларга, көрәшләргә генераль репетиция ролен дә үтәгән. Юкка гына элек Сабантуйны – ирләр, ә Җыенны хатын-кызлар бәйрәме димәгәннәрдер.

Кыпчак хатын-кызларының баш киемен сырланып килгән тәкә мөгезе рәвешендә (тормышта – киездән) эшләнгән әйберләр бизәгән. Бу бер үк вакытта югары катлам хатын-кызларның башкалардан аерылып тору билгесе дә булгандыр. Төрки мифологиядә мөгезнең мәгънәсен без алда карап узган идек инде. Ул – мәртәбәлелек, өстенлек билгесе. Моннан тыш, тәкәнең Тәңрегә корбан ителә торган хайван булуы һәм аның бүгенге татар әйтемнәрендә дә саклануы хакында тагын бер кат искә төшереп үтик.

Халык исеменең (этнонимның) тотем исеменә нигезләнүе – борынгылыкта киң таралган күренеш. Бу төрки кабиләләргә дә хас. Ул болгар кабиләләренең исемнәрендә дә урын алган. Мөгаен, болгар кабиләләреннән «бәрәнҗәрләр» – «бәрән (тәкә) җире» дигәнне, ә «аскел» «ас урыны» дигәнне аңлатадыр.

Аспарух ханның варислары саналган Дунай болгарлары «Исемлеген»дә ел хисабы 12 еллык җанвар календарендә сигезенче ел Теку (Тәкә) исемен йөртә.

Тәкә образы Тәңре, Күк белән тыгыз бәйләнештә булган һәм ул борынгы төркиләрнең космогоник карашларында да зур урын тоткан. Археологик ядкәрләрдән күренгәнчә, тәкә кояш, күк символын да чагылдырган. Шундый ядкәрләрнең берсендә түгәрәк җиз калыпка әйләнә буйлап симметрик рәвештә стильләштерелгән тәкә башлары сурәте урнашкан (рәсемдә). Уртада – схематик рәвештә эшләнгән нурлы кояш рәсеме. Дүрт тәкә башы сурәте бергә соляр тамга – кояш, ай символы булган әвернә хасил итәләр. Әйтерсең, тәкәләр кояш тирәсендә очып йөриләр.

Болгар бизәкләрендәге тәкә башлары ирексездән Көнчыгыш Алтайда казып тикшерелгән һәм иң борынгы төркиләр белән бәйле Пазырык курганнарыннан табылган рәсемнәрне күпмедер дәрәҗәдә искә төшерә. Анда тау тәкәләре башлары кояшны хәтерләтә: тәкә башларыннан әйләнә буенча кояш плазмасына, ялкын телләренә охшаш чыгымтылар сузылган. Яисә тәкә башларыннан шулай ук әйләнә буенча кызгылт җепләр таралган.

*«Сыңар мөгез күк тәкә, күктән төшеп, су эчә»*, дигән табышмак та югарыда әйтелгән фикерләр белән аваздаш. Кое сиртмәсе шул рәвешле тасвирлана. Монда тәкәнең сыңар мөгезле булуы табышмак җавабына буйсындырырга тырышу нәтиҗәсе генә. Башкорт эпосларында Киек каз юлы Мөхәммәд пәйгамбәрнең алтын мөгезле тәкәгә утырып үткән юлы буларак сөйләнелә. Бу – зур игътибарга лаек сюжет. Ул һич тә турыдан-туры ислам, Коръән белән бәйле түгел. «Мөхәммәд пәйгамбәр» соңгырак чор трансформациясе генә. Борынгы төрки мәҗүсилектә аның урынында Тәңре булган. *«Алланың (Тәңренең.– Г.Д.) кашка тәкәсе»* гыйбарәсендә тәкәнең Тәңрегә корбан хайваны гына түгеллеге яхшы аңлашыла. Күз алдына күктә бик зур мөгезле гигант кашка тәкәсе өстенә утырган Тәңре сурәте килеп баса. Башка археологик истәлекләрдәге тәкә сурәтләрендә дә мөгезләр калку итеп бирелгән. Мөгез мифларда, фольклорда җир белән күкне тоташтыручы элемент буларак күзаллана. Тарихчы Г.Фәйзрахманов мәгълүматларына караганда, Арча районы авылларында түбә кыегының алдына тәкә мөгезләре кую сирәк күренеш булмаган.

Шулай итеп, Сабантуйның традицион иң зур бүләге Тәкә – бик борынгы заманнардан килгән Тәңре белән бәйле мифологик образ. Кайчак хәзерге чор Сабантуй батырларына аның урынына мотоцикл, машина кебек нәрсәләрне бирү дә күзәтелә.

Сабан туена беренче кешелек җәмгыятьләреннән үк килгән коллективизм рухы хас. Ул хезмәт, көнкүреш белән дә бәйле. Сабантуй – универсаль бәйрәм. Бу хасияте белән ул дөнья халыкларының күп бәйрәмнәренә тартым. Әлеге сыйфат аның киң таралышына китергән дә. Ул татар халкы белән кардәш башкорт, карачай-балкар, кумык, ногай, гагауз, дунай болгарларында гына түгел, гасырлар буе ут күршеләр булып яшәгән башка халыкларда да яратып бәйрәм ителә.



*Күл-Тәгин мавзолее капкасы алдындагы тәкә сыннары. VIII гасыр.*



*Җиз камчы сабы. Биләрдән.*

*Бронза матрица. XI-XII гасырлар. Биләрдән.*

*Керамик магик җайланма – су сипкеч. Биләрдән.*

**РАБОТА СТУДЕНТАМ и ДИПЛОМНИКАМ**

НПФ БЛАГОСОСТОЯНИЕ

В один из крупнейших Российских негосударственных пенсионных фондов НПФ «БЛАГОСОСТОЯНИЕ» (российские железные дороги) требуются сотрудники на должности финансового консультанта и руководителя группы.

- оформление по договору,
- гибкий график работы, возможность совмещения,
- оплата своевременная, обучение за счет компании,
- **оклад до 20 000** +премии(оклад по результатам собеседования),

Требования: аккуратность, активность, коммуникабельность, желание зарабатывать.

**Опыт работы не обязателен !!!**

**СТУДЕНТ - НЕ УПУСКАЙ ВОЗМОЖНОСТЬ - ЗАРАБОТАТЬ И ПОЛУЧИТЬ ПЕРВОНАЧАЛЬНЫЙ ОПЫТ РАБОТЫ В СВОБОДНОЕ ОТ УЧЕБЫ ВРЕМЯ!!!**

**Все подробности:**
**г.Казань, ул Московская, 31/6, офис 203**
**или по телефонам:**
**(843) 240-18-14, 259-18-89**
**http://www.vasheblagosostoyanie.ru/**

реклама

## Илһам канатында



**Алсу Рәмис кызы СӘЛАХОВА**

Быел Яна Чишмә районы Чаллы Башы урта мәктәбенең IX сыйныфын тәмамлады. Буш вакытларыда бию түгәрәгенә йөри, театрда, төрле фәнни-гамәли конференцияләрдә катнаша. Алсу шигырьләр язарга ярата. Ул быел Бетенроссия «Илһамлы каләм» конкурсының поэзия юнәлешендә II урынга лаек булды.

### Карлар явар...

*Карлар әле күпме явар,*
*Онытылып җирне үбәр?*
*Елар...*
*Эрер...*
*Җаныбызга*
*Бер моң булып,*
*Еллар үтеп,еллар керер.*
*Кояшлардан нурлар тамар.*
*Искә төшәр,*
*Онытылыр...*
*Әкрен генә,*
*Ашыкмыйча,бер моң булып,*
*Бер җыр булып,*
*Йөрәк дигән хәтер тулыр:*
*Искә төшәр...*
*Онытылыр...*

### Бу минем туган илем

*Зәңгәр күк, яшел болыннар,*
*Әнидәй назлы җиле...*
*– Ни? – дисәгез, мин әйтермен:*
*– Бу – минем туган илем!*

*Сары,ак,күксел чәчәкләр,*
*Төнбоек моңы күлдә.*
*– Кайда? – диеп сорасагыз,*
*Әйтермен: – Туган илдә!*

*Һәр почмагы миңа якын,*
*Әтидәй батыр, көчле.*
*– Нәрсә? – диеп сорамагыз,*
*Бу – минем туган илем!*

### Һөнәр сайлыйм...

*Сабыйлыкның ак битләрен ябам:*
*Мин җаваплы кеше бүгеннән.*
*Йолдыз түгел, төпле киңәш чуплим*
*Тормышымның якты күгеннән.*

*Ниләр диеп тибә соң бу йөрәк?*
*Нәрсәләрсез җирдә торалмый?*
*Һөнәр сайлыйм, тормыш дәфтәремне*
*Төрле төсләр белән чуарлыйм.*

*Болытларга бик еш менә күңел,*
*Чиста биткә зәңгәр сызыла...*
*Табибларга һәрчак сокланамын:*
*Ихтыярсыз ак юл сузыла...*

*Чәчәкләргә хушсыз гашыйк булдым,*
*Һәр тереклек миңа бик якын –*
*Алсу төскә манам пумаламны:*
*Дәфтәремне ала ут-ялкын.*

*Ижатка да битараф була алмыйм –*
*Ачык сары бизи битемне...*
*Рәсемемдә минем туган ягым!*
*Таптым, ахры, мин үз бәхетемне.*

*Бу тормышта үз-үзеңне эзләү*
*Алсу күзлекләрдән башлана.*
*Туган якка ихлас мәхәббәтең*
*Йөрәгеңдә мәңге саклана.*


### Көзге яфрак

*Бии, оча һәм әйләнә,*
*Күбәләктәй күккә менә,*
*Салкын җирне төшеп үбә –*
*Көзге яфрак җирне күмә.*
*Әйтерсең лә җил-музыкант*
*Һава белән уйный бирә.*
*Вальс көенә бөтерелә –*
*Көзге яфрак җирне төрә.*
*Кызыл күлмәкләрен кия,*
*Серле булып кала бирә,*
*Танымаслар әле дия –*
*Көзге яфрак гүя түрә.*

*Елгаларда сәяхәт итә,*
*Җирләр күрә, нурлар эчә,*
*Кызыксыну аны җиңә –*
*Көзге яфрак диңгез кичә.*
*Көзләр үтеп, кышлар килә,*
*Ә җил саксафоның өрә.*
*Җджазны өнәмәгәнгә күрә,*
*Яфрак туктый – карлар көлә.*

## Дөнья үзебезнеке

# Үзеңне тап!



**Алмаз Мансуров,**
татар филологиясе бүлеге студенты

Һәр чорның үз студенты була. Тик студентлар арасындагы язылмаган кануннарга буйсынып бүлену беркайчан да бетмәстер, мөгаен...

*«Атлар» — гыйлем арбасын сөйрәүче студентлар. Үз эшләрен намуслы башкаралар,ярты ел дәвамында йөкне тырышып өстериләр. Имтиханнар җиткәч,арбаны бушатып,сынауларны җиңел генә узалар һәм беренчелекне яулыйлар.*

*«Абзыйлар» — «атлар» сөйрәгән гыйлем арбасында кырын ятучылар. Уку дәверендә «атларны» куалыйлар. Аларга ялынып, ялварып,алай да барып чыкмаса,аларны куркытып,максатка ирешәләр. Төп эшләре — башкалардан күчерү. Имтиханнарны СМСлар ярдәмендә биреп,яхшы гына билгеләр алып чыгалар.*

*«Төлкеләр» — хәйләкәр студентлар. Тиз-тиз хәрәкәт итүче,ялтырап торган күзле егет-кызлар. Шпаргалка язуның һәм аны яшереп кенә имтиханга алып керүнең чын осталары.*

*«Песиләр» — укытучыларның яраткан студентлары. Алар йомшак,назлы,игътибарлы. Укытучы янында сырпаланып йөрергә яраталар. Шуңа күрә дә «уку» дигән сикәлтәле юлларны җиңел узалар,«имтихан» үрләрен дә беренче тапкырдан ук яулыйлар.*

*«Ташбакалар» — артта калучылар. Барлык эшләрне дә зур авырлык белән башкаралар. Билгеле инде,модуль,имтихан,зачётларны кат-кат тапшыралар.*

*«Акчарлаклар» — чын философлар. Алар иң кирәген генә,гыйлемнең каймагын гына җыялар. Укытучыга җавап биргәндә,хыял күген иңләп,фәлсәфәгә бирелеп,мантыйгый нәтиҗәләр ясап сөйлиләр.*

*«Солдатлар» барысын да алдан кайгырталар. Ел башында «хәрби» максат куялар,аңа ирешү юлларын эзләп,яшерен план төзиләр. Режим буенча яшиләр. Эчке сиземләүләренә таянып эш итәләр. Шуңа күрә дә укытучылар еш кына аларга «автомат» бүләк итә.*

## Сәламәтлек

# Көн - эшләргә, төн - йокларга!

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

Студентлар – бик тырыш халык, көн дәвамында алар бик күп нәрсәгә өлгерә: парага бара, кайберләре аннан соң эшкә чаба, кайткач өй эшләрен эшли, күңел ачарга да вакыт таба. Мондый тыгыз графикта йокыга вакыт кала микән? Организмга ял итеп, яңа көнгә хәл җыярлык вакыт биреләме соң?



Җитәрлек дәрәҗәдә йокламау студентларның гына түгел, бөтен кешелекнең чиренә әйләнеп бара. Кызганычка каршы, кешеләр йокыга дигән 8 сәгатьне тиешенчә кулланмыйлар. Быелның март аенда үткәрелгән интернет сораштыру нәтиҗәсендә түбәндәге фактлар ачыкланган: Рәсәй халкының яртысыннан күбесе ким дигәндә атнага бер тапкыр йокысын туйдырмый, шуларның 32% көн саен яисә көнаралаш йокысызлыктан тилмерә, 2% бөтенләй дә йокының туйганы юк дип әйтә.

Йокы туймаганлык аркасында реакциянең кимүен, шуның нәтиҗәсендә игътибарсызлык, хәлсезлек, гел йокы килү халәтләре барлыкка килү һәр кешегә мәгълүм. Шуларга өстәп, йокысызлык галәмәтенең ахыры тагы да аянычлы булырга, бик күп авырулар китереп чыгарырга мөмкин. Кешенең организмында яшьлеген саклап калуда мөһим роль уйный торган мелатонин гармоны бар. Аның бүленеп чыгуының 70% төнгә туры килә, бигрәк тә төнге сәгать икеләргә. Шуннан чыгып, йокы сәгатенең аз булуы мелатонинның да кимүенә китерә, ә ул, үз чиратында, вакыттан алда картаюга китереп чыгарырга мөмкин.

Төнге йокы сәгатьләренең җитмәве яман шеш авыруын да барлыкка китерергә мөмкин, бигрәк тә юан эчәклектә. Әлеге процесс та мелатонин белән бәйләнгән. Бу гармон яман шеш күзәнәкләренең үрчү мөмкинлекләрен киметә.

Күптән түгел генә галимнәр йокы сәгате кимү белән диабет арасында бәйләнеш тапканнар. Организмга йокы җитмәү сәбәпле, ул кандагы глюкозаның микъдарын контрольләп бетерә алмый һәм шуның нәҗитәсендә диабетның икенче төре барлыкка килергә мөмкин.

Чикаго университеты галимнәре тикшеренүләренә караганда, 5 ел буена көнгә 1 сәгать йокыны киметү гипертония үсешен 37% арттыра. Шул ук галимнәр иртәнге 8-9дан берәр сәгатькә алдан торган кешеләрнең югары кан басымыннан интегүен һәм матдәләр алмашыну процессы бозылуын искәртәләр.

Йокысызлык ир-егетләр өчен бигрәк тә аянычлы нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Атна буе йокыны туйдырмау (көн саен 5 сәгать кенә йоклау) аларның организмын 10-15 елга картайта.

«Урланган» 1-2 сәгать йокы иммунитетның да көчсезләнүенә сәбәпче булырга мөмкин. Америка галимнәре үткәргән тәҗрибәләрнең нәтиҗәсенә күз салсак, көненә 7 сәгатьтән кимрәк йоклаган кешеләрнең салкын тидерү куркынычы 8 сәгать йоклаганнар белән чагыштырганда 3 тапкырга югарырак икән.

Иммунитетка гына йогынты ясап калмыйча, психик сәламәтлегебезгә дә зыян килергә мөмкин. Кеше сабырсызлана, тиз кызып китүчәнгә әйләнә, аңа игътибарын бер әйбергә генә тупларга бик авыр. Шуның белән бергә баш миенең дә эшчәнлегенә көч килә: ул мәгълүматны кабул итү сәләтен югалтмый, әмма аны бозып эшкәртергә мөмкин.

Ял көннәрендә без «атна буе йокламаганны чыгарыйк», дип, озаграк йокларга яратабыз. Табиблар әйтүенчә, аз йоклау белән беррәттән озак йоклау да безнең организмыбызга зыян китерә. Шуңа күрә һәр көн саен бер үк вакытта ятып, бер үк вакытта торуны режимга кертергә кирәк. Организм белән баш мие көне буена җыйган мәгълүматтан арынырга тиеш. Ял итү өчен дә вакытны җәлләмәсәк иде.






DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.